ГЛАВА КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.16, д.Пойкино, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Октябрь ур., 16 нче йорт, Пойкино авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-19; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар  
“21” октябрь 2020 ел.

Постановление  
№ 5

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Сарбаш авылы Яшел урамы , 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Сарбаш авылы клубында 2020 елның 11 ноябрендә 08.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хэрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хэрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр,көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Сарбаш торак пунктындагы керү юлын вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
-Сарбаш торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башкарма комитетына Сарбаш торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге башлыгы: Б.В.Иванов